Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Яңа Чишмә авыл җирлегенең Яңа Чишмә авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2022 елның 16 ноябре № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2022 елның 1 ноябрдә 09.00 сәгатьтә, 1 ноябрдә 10.00 сәгатьтә, 1 ноябрдә 11.00 сәгатьтә, 1 ноябрдә 13.00 сәгатьтә, 1 ноябрендә 14.00 сәгатьтә, 2 ноябрдә 07.00 сәгатьтә, 2 ноябрдә 08.00 сәгатьтә, 2 ноябрдә 10.00 сәгатьтә, 2 ноябрдә 13.00 сәгатьтә, 2 ноябрдә 14.00 сәгатьтә, 3 ноябрдә 07.00 сәгатьтә, 3 ноябрдә 08.00 сәгатьтә, 3 ноябрдә 10.00 сәгатьтә, 3 ноябрдә 13.00 сәгатьтә, 3 ноябрдә 14.00 сәгатьтә, 8 ноябрдә 09.00 сәгатьтә, 8 ноябрдә 13.00 сәгатьтә, 8 ноябрдә 14.00 сәгатьтә, 9 ноябрдә 08.00 сәгатьтә, 9 ноябрдә 09.00 сәгатьтә, 9 ноябрдә 13.00 сәгатьтә, 9 ноябрдә 15.00 сәгатьтә, 10 ноябрдә 07.30 сәгатьтә, 10 ноябрдә, 14.00 сәгатьтә, 11 ноябрдә 9.00 сәгатьтә, “Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Яңа Чишмә авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ кешедән, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 1 группа инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннарыннан, өлкәннәр һәм инвалидлар өчен интернат-йортта яшәүче гражданнардан, 85 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан һәм Россия Федерациясе Кораллы көчләренә мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш 300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм жыелган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне:

- Яңа Чишмә авылының Чернышевский, Шмидт, Яшьләр, Бакча, Тирәкле, Мәктәп, Октябрь, Тихонов, 2 нче Яр буе, Горький, Попов урамнарында контейнер мәйданчыкларын төзү һәм реконструкцияләү (материаллар сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Төзүчеләр урамында тротуар төзү (материаллар сатып алу, вак таш, асфальт, бордюрлар салу, килешү буенча эшләр өчен түләү) хәл итүгә ризамы ” дигән сорауга жавап бирү буенча гражданнар җыенының нәтиҗәләре белән йомгаклау беркетмәсе төзелде.

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 3695 кеше, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 2246 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

җыенда катнашкан 2060 кеше «ӘЙЕ» позициясе өчен тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашкан 186 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Яңа Чишмә авыл җирлегенең Яңа Чишмә авылында халык җыенын узган дип танырга.

2. «2023 елда Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Яңа Чишмә авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ кешедән, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннарыннан, 85 яшьтән өлкәнрәкләр һәм өлкәннәр өчен интернат-йортта яшәүче гражданнардан һәм Россия Федерациясе Кораллы көчләренә мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм жыелган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган әлеге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- Яңа Чишмә авылының Чернышевский, Шмидт, Яшьләр, Бакча, Тирәкле, Мәктәп, Октябрь, Тихонов, 2 нче Яр буе, Горький, Попов урамнарында контейнер мәйданчыкларын төзү һәм реконструкцияләү (материаллар сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);

- Төзүчеләр урамында тротуар төзү (материаллар сатып алу, вак таш, асфальт, бордюрлар салу, килешү буенча эшләр өчен түләү) дигән сорау буенча карарны кабул итәргә.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Яңа Чишмә авыл җирлегенең Яңа Чишмә авылы мәгълүмат стендларында, Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru һәм хокукый мәгълүматның рәсми сайтында http://pravo.tatarstan.ru кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Яңа Чишмә авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Яңа Чишмә муниципаль районы Яңа Чишмә
авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе Т. Н. Маланчева